КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

2024 ел, 14 ноябрь г.Казань № б-2482

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2023 ел, 17 ноябрь, б-2559 нчы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы төшереп калдырырга;

1 пунктның дүртенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге боерык белән расланган «Театраль Идел буе» балалар һәм яшьләр театр коллективлары фестиваленең республика сайлап алу этабын әзерләү һәм үткәрү буенча оештыру комитеты составында:

оештыру комитеты составыннан Ф.Р.Бикчәнтәевны, Л.Н.Шарованы чыгарырга;

оештыру комитеты составына «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Илнур Зөфәр улы Гайниевны кертергә;

әлеге боерык белән расланган «Театраль Идел буе» балалар һәм яшьләр театр коллективлары фестиваленең республика сайлап алу этабының экспертлар советы (жюри) составында

экспертлар советы (жюри) составыннан Ф.Р.Бикчәнтәевны, Л.Н.Шарованы чыгарырга;

экспертлар советы (жюри) составына «Габдулла Кариев исемендәге Казан татар дәүләт яшь тамашачы театры» дәүләт бюджет учреждениесе директоры Илнур Зөфәр улы Гайниевны кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин